Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советының утыз алтынчы утырышы

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

23 ноябрь, 2023 ел № 273

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районында бюджет процессы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карар кабул итте:**

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының 2019 елның 24 октябрендәге 217 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районында бюджет процессы турында Нигезләмәгә (Советның 2020 елның 30 июлендәге 279 номерлы, 09.09.2021 елның 9 сентябрендәге 98 номерлы, 2022 елның 12 маендагы 159 номерлы, 2023 елның 18 маендагы 232 номерлы карарлары белән расланган үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

39 статья «Муниципаль юл фонды» яңа редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль юл фонды район Советы карары белән төзелә.

Муниципаль юл фондының бюджет ассигнованиеләре күләме район Советы карары белән билгеләнгән район бюджеты керемнәренең фаразлана торган күләменнән ким булмаган күләмдә чираттагы финанс елына (чираттагы финанс елына һәм план чорына) җирле бюджет турында карар белән раслана:

- автомобиль бензинына акцизлар, турыдан-туры куылган бензин, дизель ягулыгы, Россия Федерациясе территориясендә җитештерелә торган дизель һәм (яисә) карбюратор (инжектор) двигательләр өчен мотор майлары;

- җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына авыр йөкле транспорт чаралары китерә торган зыянны каплау исәбенә җирле бюджетларның керемнәре;

- авыр йөкле һәм (яисә) эре габаритлы транспорт чарасының хәрәкәт итү кагыйдәләрен бозган өчен җирле бюджетларның керемнәре;

- муниципаль юл фонды төзүне күздә тоткан район Советы карары белән расланган җирле бюджетка башка кертемнәр.

Муниципаль юл фондының бюджет ассигнованиеләрен формалаштыру һәм куллану тәртибе район Советы карары белән билгеләнә.

Агымдагы финанс елында файдаланылмаган муниципаль юл фондының бюджет ассигнованиеләре чираттагы финанс елында муниципаль юл фондының бюджет ассигнованиеләрен арттыруга җибәрелә.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Питрәч муниципаль районы башлыгы И.М. Кашапов